**5 нче сыйныф**

**Татар әдәбиятыннан тест**

Татар халык авыз иҗаты

**1.«Фольклор» сүзе нәрсәне аңлата?**

а) халыкның телдән сөйләнә торган поэтик әсәрләре;

ә) халык авыз иҗатының төп жанрларыннан берсе;

б) әдәп-әхлак, акыл өйрәтүгә нигезләнгән кыска әсәр.

**2. Түбәндәге юллар фольклорның кайсы төренә карый?**

Ай белән килә,

Көн белән китә,

Алтын башлы,

Көмеш чәчле,

Мең дә бер яшьле.

а) санамыш;

ә) әкият;

б) табышмак.

**3. Түбәндәге юллар кайсы шагыйрьнеке?**

«Халык — зур ул, көчле ул, дәртле ул, әдип ул, шагыйрь ул».

а) Абдулла Алиш;

ә) Габдулла Тукай;

б) Кол Гали.

**4. Нәрсә ул санамыш?**

а) лиро-эпик жанрның берсе, текст шигъри формада була, телдән әйтелә яки көйләп башкарыла;

ә) балалар уенын башлаганда тәртип билгеләү һ. б. өчен әйтелә торган кыска такмак;

б) уен-бию җырларының тотрыклы кушымта өлеше.

**5. «Мәкаль» сүзенең билгеләмәсе кайсы?**

а) кыска, образлы, шигъри формадагы, гыйбрәтле, тормыш итү тәҗрибәсенә нигезләнгән халык авыз иҗаты әсәре;

ә) аллегорик характердагы, ягъни читләтеп әйтүгә, кинаягә корылган, гыйбрәтле, акыл-әхлак өйрәтә торган кечкенә хикәя;

б) кечкенә күләмле, эмоциональлеге, ритмик төзелеше белән шигъри сөйләмгә якын булган, лирик-патетик характердагы проза әсәре.

**6. Халык авыз иҗаты әсәрләренең авторы кем?**

а) балалар;

ә) шагыйрь һәм язучылар;

б) халык.

## Ачкыч

1. **А**
2. **Б**
3. **Ә**
4. **Ә**
5. **А**
6. **Б**

# Бәяләү

**5-6 балл – “5”ле**

**4 балл – “4”ле**

**3 балл – “3”ле**